КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 18 июль г.Казань № 858

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясен төзү турында» 2003 ел, 29 май, 295 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 май, 364 нче, 2019 ел, 16 июль, 584 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының тәңгәллеген билгеләү комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның өченче абзацында «дәүләт хакимияте һәм идарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин